| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

| **РЕШЕНИЕ**<br>**14.12.2017** | Зеленодольск ш. | **КАРАР**<br>**№ 160** |
|---|---|---|

2017 елда һәм 2018 елгы планда “2016-2026 елларга ишегалды стандарты" программасын үтәүнең барышы

«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе житәкчесе вазыйфаларын башкаручы И. В. Благовещенскийның 2017 елда һәм 2018 елгы планда «2016-2026 елларга ишегалды стандарты» программасын үтәүнең барышы турындагы мәгълүматын тыңлаганнан соң, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1.2017 елда һәм 2018 елгы планда "2016-2026 елларга ишегалды стандарты" программасын үтәүнең барышы турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1 “2016-2026 елларга ишегалды стандарты» программасына “2016-2026 елларга ишегалды стандарты» программасында катнашучы күпфатирлы йортларда видеокүзәтү системаларын урнаштыруга милекчеләрнең ризалыгы белән сайлап алу критерийларын өстәү өлешендә тиешле үзгәрешләр кертергә.

2.2 “2016-2026 елларга ишегалды стандарты» программасы кысаларында 2018 елда планлаштырылган эшләр турындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырырга.

Шәһәр төзелеше, торак сәясәте, төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт мәсьәләләре буенча Зеленодольск шәһәр Советының 3 даими комиссиясе үз утырышларында “2016-2026 елларга ишегалды стандарты» программасын үтәү барышын карап торырга тиеш.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**